**УКАЗ**
ПРЕЗИДЕНТА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ПРЕЗИДЕНТЫ
**УКАЗЫ**

**Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы Инвестиция советын төзү турында» Указына үзгәрешләр кертү хакында**

Татарстан Республикасы Инвестиция советы эшчәнлеген камилләштерү максатларында **карар бирәм:**

1. Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы Инвестиция советын төзү турында» 2012 елның 5 июлендәге ПУ-538 номерлы Указына (Татарстан Республикасы Президентының 2012 елның 6 сентябрендәге ПУ-745 номерлы, 2012 елның 3 ноябрендәге ПУ-914 номерлы, 2013 елның 20 мартындагы ПУ-242 номерлы, 2013 елның 29 мартындагы ПУ-258 номерлы, 2013 елның 8 августындагы ПУ-717 номерлы, 2014 елның 29 апрелендәге ПУ-440 номерлы, 2014 елның 27 августындагы ПУ-826 номерлы, 2015 елның 2 мартындагы ПУ-199 номерлы, 2015 елның 13 октябрендәге ПУ-984 номерлы, 2016 елның 29 июнендәге ПУ-553 номерлы, 2017 елның 8 июнендәге ПУ-480 номерлы, 2018 елның 4 сентябрендәге ПУ-612 номерлы һәм 2019 елның 8 февралендәге ПУ-90 номерлы указлары нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

а) Татарстан Республикасы Инвестиция советы турында нигезләмәнең 8 пункты беренче абзацында «Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнары,» сүзләреннән соң «Татарстан Республикасының башка дәүләт органнары вәкилләре,» сүзләрен өстәргә;

б) Татарстан Республикасы Инвестиция советы (алга таба – Инвестиция советы) составында:

Инвестиция советы составыннан А.Р. Бәшировны, Р.Г. Кантюковны, А.К. Хамаевны чыгарырга;

Инвестиция советы составына кертергә:

Агиев Шамил Рәхим улын – Татарстан Республикасы Сәүдә-сәнәгать палатасы идарә рәисен (килешү буенча);

Әгълиуллин Фәнил Әнвәр улын – Татарстан Республикасы җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрын;

Мирзакриев Рөстәм Рәүф улын – Татарстан Республикасы Президенты ярдәмчесен;

Усманов Рөстәм Ринат улын – «Газпром трансгаз Казан» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте генераль директорын (килешү буенча).

2. Әлеге Указ аңа кул куйган көннән үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы Президенты** **Р.Н. Миңнеханов**

ГОМУМИ БҮЛЕК
ОБЩИЙ ОТДЕЛ
ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ АППАРАТЫ * АППАРАТ ПРЕЗИДЕНТА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

Казан, Кремль
2019 ел, 12 октябрь
№ ПУ-619